**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯХШЫЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам, 18 нче йорт.
Тел.(885552)3-44-45.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423765, с. Верхнее Яхшеево, ул. Новая,
дом 18.  Тел.(885552) 3-44-45.
E-mail Diliya.Mirzaeva@tatar.ru

**КАРАР** | **РЕШЕНИЕ**

**11 ноябрь 2024 ел** | **№4**

**Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлегенең
Югары Яхшый торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 11 ноябрендә Югары Яхшый авылы җирлегенең Югары Яхшый торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Бу мәсьәлә буенча: “2025 елда Актаныш муниципаль районының Югары Яхшый авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,  Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 1 төркем инвалидлардан,  хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм махсус хәрби операциядә  катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, җирлектә түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән узара салым акчасын 600 сум күләмендә билгеләргә ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау (җылыту, кардан чистарту һәм башкалар));

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен тоту һәм ремонтлау);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (койманы ремонтлау һәм төзекләндерү
хуҗасыз территорияләрнең коймасын урнаштыру;

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (су үткәрү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау, су анализы) системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

«риза» -89, «каршы» «тоткарланучылар»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 112 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 89 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"риза" позициясе өчен 89 граждан тавыш бирде;
"каршы" позициясе өчен - 0 граждан тавыш бирде.
"тоткарландылар" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Югары Яхшый торак пунктында, Югары Яхшый авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Югары Яхшый авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары булган гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга 600 сум күләмендә узара салым билгеләргә ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау (җылыту, кардан чистарту һәм башкалар));

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен тоту һәм ремонтлау);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм койманы урнаштыру);

- Кабул ителгән су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (су үткәрү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау), су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

3. Әлеге карарны Югары Яхшый авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru.

Югары Яхшый авыл җирлеге башлыгы И.Х.Әхәтов